РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
ЛЬЯШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛЬЯШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

тел. (84373) 55-8-26, факс 55-8-26

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**22 .11. 2021** **№ 1**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Льяшево авыл җирлегенең Ямбухтино торак пунктында 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Льяш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 ст. нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Ямбакты авылы, Заречная урамы, 20 Б йортта 2021 елның 6 декабрендә 15 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Ямбакты авыл мәдәният йорты бинасында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә акча кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Ямбакты т. п. Заречная ур., Слободская ур.;

- Ямбакты т. п . урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, агымдагы ремонт һәм урам утларына хезмәт күрсәтү) ;

- юлларны кардан чистарту , грейдлау (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);».

«КАРШЫ» “РИЗА”

3. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Льяшево авыл җирлеге башкарма комитеты Гражданнар җыенын оештырырга һәм үткәрергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Льяшево авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга. https://tetushi.tatarstan.ru/

5. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Льяшево авыл җирлеге башкарма комитеты Гражданнар җыенын үткәргәндә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Льяшево авыл җирлеге территориясендә яңа коронавирус йогышы

(COVID-19) белән авыру очракларын кисәтү һәм тарату өчен профилактик, санитар-эпидемиологик чараларның үтәлешен тәэмин итәргә.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Җитәкче** **И.А. Тихонова**